ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 декабрь 2020 ел № 7326

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы 7 пункты, 72 статьясы 2 бүлеге, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча расларга.

2. Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия (алга таба – комиссия) төзергә.

3. Расларга:

1) комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымтада каралганча;

2) комиссия составын 3 нче кушымтада каралганча.

4. Башкарма комитетның финанс идарәсенә:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүне финанслауны 2020 елга шәһәр бюджетының «Гомумдәүләткә караган башка мәсьәләләр» 01.13 бүлегендә каралган акчалар хисабына 5 300 мең сум күләмендә тәэмин итәргә;

2) чираттагы финанс елына шәһәр бюджетын үтәгәндә әлеге пунктның 1 пунктчасында каралган максатларга акча бүлеп бирү мөмкинлеген карап тикшерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 25 декабрендәге
7326 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында
нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына тиешле елда Яр Чаллы шәһәре бюджет акчалары чикләрендә аларга акчалата ярдәм күрсәтү максатларында бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүнең тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләме һәр алучыга 100 000 (йөз мең) сум күләмендә билгеләнә.

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучылар тарафыннан Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Законы кысаларында сатып алына торган торак өчен түләү буенча бурычларны түләүгә җибәрелә.

3. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъвачылар булып Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче, ТР Министрлар Кабинетының 2014 елның 25 февралендәге 120 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гранты алган һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе белән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелгән елдан алда килгән елда хезмәт шартнамәсе төзегән табиб-белгечләр, клиник-лаборатор диагностика табиблары санала.

4. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъвачыларны сайлап алуның төп критерие булып Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе белән хезмәт шартнамәсе төзү датасы һәм Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Законы кысаларында сатып алына торган торак өчен түләү буенча үтәлмәгән шартнамә килешүе йөкләмәләре булу санала.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъвачыларның гаризаларын карап тикшерү эшен оештыру Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү буенча комиссиягә (алга таба – комиссия) йөкләнә.

Комиссия турында нигезләмә, аның составы Башкарма комитет карары белән раслана.

6. Башкарма комитет Җитәкчесенең Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре белән үзара эшчәнлек өчен җаваплы урынбасары Башкарма комитетның әлеге нигезләмәне раслаган карары чыккан көннән башлап 3 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга гаризалар җыя башлау турында әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган документларны җибәрү срогын һәм комиссия утырышының датасын күздә тоткан белдерү кәгазе (алга таба – белдерү кәгазе) җибәрә.

7. Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе белдерү кәгазендә билгеләнгән срокта комиссиягә түбәндәге документларны җибәрә:

1) табиб-белгечнең (клиник-лаборатор диагностика табибының) Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында гаризасы;

2) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъвачының шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

3) табиб-белгеч (клиник-лаборатор диагностика табибы) һәм Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе арасында төзелгән хезмәт шартнамәсенең күчермәсе;

4) Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә кабул ителгән табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантын бирү турында шартнамә күчермәсе;

5) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Законы кысаларында торак сатып алу турында шартнамә күчермәсе.

Документларның күчермәләре комиссия секретаре тарафыннан расланырга тиеш.

8. Комиссия әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган документларны өч эш көне эчендә карап тикшерүне гамәлгә ашыра. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

9. Алучыга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

2) алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөреслеккә туры килмәү факты ачыклану.

10. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү өчен нигез булып Башкарма комитет һәм бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучы арасында комиссия беркетмәсе нигезендә төзелгән шартнамә тора.

11. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучылар күрсәтелгән акчаларны әлеге нигезләмәнең 2 пунктында каралган максатларга җибәргән көннән башлап 15 эш көне эчендә комиссия секретаренә әлеге түләүдән максатчан файдалануны раслаучы документлар (түләү йөкләмәләре, шартнамәләр) тапшыралар.

Комиссия секретаре әлеге пунктның беренче абзацында каралган документларны карап тикшерә һәм аларны өч эш көне эчендә карап тикшерү өчен Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.

12. Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре белән үзара эшчәнлек өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары һәм Башкарма комитетның финанс идарәсе, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән тәртиптә, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең алучылар тарафыннан максатчан файдаланылуын контрольдә тота.

Акчалардан максатчан файдаланмаган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү, Башкарма комитет тарафыннан тиешле таләп куелганнан соң 10 эш көне эчендә, шәһәр бюджетына кире кайтарыла.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы — А.Ф. Бареева

Башкарма комитетның
2020 елның 25 декабрендәге
7326 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы
дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә,
клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр
бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия турында
нигезләмә

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия (алга таба-комиссия) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Законын гамәлгә ашыру кысаларында сатып алына торган торак өчен түләү буенча бурычларны түләүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бүлү турында объектив карар кабул итү максатларында төзелде.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә әлеге нигезләмәгә һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең сан ягыннан һәм персональ составы Башкарма комитет карары белән раслана.

4. Комиссия әгъзалары хокуклы:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;

3) комиссия утырышында катнашырга;

4) комиссия карап тикшерүенә чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;

5) карап тикшерү өчен чыгарылган мәсьәлә буенча фикер белдерергә.

5. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

2) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны имзалый.

6. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара.

7. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиянең эш кәгазьләрен алып бара;

2) комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;

3) комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмати материаллар белән тәэмин итә;

4) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара.

8. Комиссия утырышы аның составының кимендә өчтән икесе катнашса хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары утырышта шәхсән үзләре катнаша. Комиссия әгъзасы утырышта булмаган очракта карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

9. Комиссия карарлары тапшырылган документларны карап тикшерү һәм түләүне бирү тәртибе таләпләренә туры килү-килмәү нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен комиссия әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

10. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

11. Комиссия карары комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева

Башкарма комитетның
2020 елның 25 декабрендәге
7326 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы
дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә,
клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр
бирелә торган акчалата түләүне бүлү буенча комиссия составы

| Вазыйфаи затның Ф.И.А.и. | вазыйфасы |
|---|---|
| Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| Хәлимов Рамил Мәрван улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| комиссия әгъзалары: | |
| Мулюкова Светлана Рафаиль кызы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| Мөхәмәдиев Марат Фәнис улы | Шәһәр Советы депутаты, «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Николаев Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хөсәенова Альбина Шамил кызы | комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге консультанты (килешү буенча) |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы




А.Ф. Бареева